Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге Татар Тау Иле авылы
Белкино, Яңа, Төзүчеләр урамы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

15 ноябрь, 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге Татар Тау Иле авылы Белкино, Яңа, Төзүчеләр урамы гражданнарының 2023 елның 15 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 92 (туксан ике).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 48 (кырык сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 48 (кырык сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2024 елда Татар Тау Иле авылы Белкино, Яңа, Төзүчеләр урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларны, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, ВОВ һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- юлларны ремонтлау» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татар Тау Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Хөсәенов